**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Сәвәләй авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**№37** **15.07.2021**

**«Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 15 нояброндәге 161 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Сәвәлей авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 25 нояброндәге 161 номерлы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 17 апреляндәге 242а номерлы, 2018 елның 29 маендәге 141 номерлы, 2019 елның 05 ноябрендәге 214 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9 бүлекнең 2 абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 20 бүлекнең 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Җирле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет турында карар проекты кертелгәннән соң кабул ителгән җирлек Советының муниципаль хокукый актлары нигезләмәләре агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә чираттагы финанс елында, агымдагы финанс елына һәм план чорына, агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә исәпкә алына.";

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Сәвәләй авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **С.К.Маклаков**